# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Иске Матвеевка авыл җирлегенең Иске Матвеевка торак пунктында
2026 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

№ 2 24 ноябрь 2025 ел.

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Иске Матвеевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Иске Матвеевка торак пунктында халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Иске Матвеевкка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган кешедән (I төркем инвалидлардан, БВС һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, БВС сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның толларыннан, купбалалы гаиләләрдән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләрдән, СВОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш) 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Иске Матвеевка торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (юл читләрен һәм янәшәдәге территорияләрне чабу, В.Гордов урамына койма сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

2) Иске Матвеевка торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урам яктырту лампочкаларын алмаштыру, фото реле һәм вакыт реле сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) – кабул ителде.

Халык җыены нәтиҗәләрен Иске Матвеевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге сайтында http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга http://pravo.tatarstan .

Халык җыенында рәислек итүче,
Башлык: Д.Ш.Латыйпов